СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

ул. Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Арча муниципаль районы**
**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**«19» август 2026 ел** **№ 20**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең генераль планын әзерләүгә ихтыяҗ булмавы турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 нче маддәсенең 6 нчы пункты нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә авыл җирлеге территориясен куллануның гамәлдәге тәртибен үзгәртү күздә тотылмаганлыктан, комплекслы социаль-икътисади үсешнең расланган программасы булмау сәбәпле, Татарстан Республикасының һәм Арча муниципаль районының территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмаганлыктан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең генераль планын 2027 елның 1 июленә кадәр эшләүгә ихтыяҗ булмавын танырга.
2. Бу карар 2026 елның 1 августыннан башлап килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Бу карар Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Иске Чүриле авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Рамазанов